**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«20»_12_______2019ел** Чирмешән авылы **№____533________**

**Ваклап сату базарын оештыру**
**хокукына рөхсәт бирү буенча**
**муниципаль хезмәт күрсәтүнең**
**административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.

2.Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 декабрендәге 599 номерлы «Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны районның Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

Килешенде:
Район Башкарма комитеты җитәкчесенең
икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары — М.Х. Әһлиуллин

Тикшерде:
Муниципаль район Советының
юридик бүлек начальнигы — Т.В. Рунова

Әзерләде:
Территориаль үсеш бүлеге
җитәкчесе урынбасары — Л.Ф.Җиһаншина